РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН СОВЕТ
НОВОЧЕЧКАБСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА ЧӘЧКАП
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

13 октябрь 2021 ел № 1-31

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районы Яңа Чәчкап авыл җирлегендә бюджет
процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр
кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә , Буа муниципаль районы Яңа Чәчкап авыл җирлеге Советы

РЕШИЛ:

1. 2018 елның 16 июлендәге 51-2 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Яңа Чәчкап авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» (12.05.2020 ел, № 83, 19.08.2020 ел, № 89-1, 20.10.2020 ел, № 2-4, 15.09.2021 ел, № 1-28 карарлар редакциясендә) карары белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Яңа Чәчкап авыл җирлегендә бюджет процессы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 5 статья:

10 пунктның 4 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«бюджет кытлыгын финанслау чыганакларын түләү өчен бүлеп бирелгән ассигнованиеләрне, бюджетның бердәм счетында калдыклар белән идарә итү операцияләреннән тыш, адреслы һәм максатчан характерда кулланылуны тәэмин итә;».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм җирлекнең рәсми сайтында Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Буа муниципаль районы
Яңа Чәчкап авыл җирлеге башлыгы Д.Д. Абдрахманова